

Авыл хужалыгы тармагы Мордовия икътисадында һәрчак vзенә бер урын билəде. Бvгенге кондә ул аеруча зур vзгәрешләр кичерә: житештерv һәм эшкәртv тармагында алдынгы технологияләр куллану, оешмаларны модернизацияләv, яна хужалыклар, шул исәптән фермерлык хужалыклары оешу - монын ачык мисалы. Ләкин нинди генә яна технологияләр уйлап табылмасын, һәрчак хезмәт кешеләренен тәжрибәсенә һәм тырышлыгына таянылa: жиргә карата хужаларча монәсәбәт, жаваплы булу белән агросәнәгать комплексы vсеше очен унай шартлар тудырыла.
Ата-бабаларыбыз гомер-гомергә, буыннан-буынга эшләп, һәрвакыт зур унышларга, зур терлекчелек продукциясенә омет баглап яшәде. Әйтергә кирәк, авыл халкынын бvген дә нинди хезмәт куйганнарын истә тотып, ризыкнын ничек итеп остәлгә килеп эләккәнен, мул уныш очен тырышуларын кvреп, матур уныш бәйрәме барлыкка килгән.
Республикабыз агросәнәгать комплексы хезмәтчәннәре, авыл хужалыгы тармагы һонәри бәйрәме – авыл хужалыгы һәм эшкәртv хезмәтчәннәре конена багышланган очрашуда Владимир Волков аларны ихластан котлады һәм тантаналы производство алдынгыларын хормәт итеп бvләкләде.       Бvләк алучылар арасында производствода зур унышларга ирешкән Ельник районы ООО «За мир» директоры Шамиль Кәрим улы Мещеров та бар иде.
Анын турында. Шамиль Кәрим улы Мещеров Ельник районы Кvгеш – Акчеево авылы кешесе - гомере буе Ельник «Сельхозхимия»сендә тракторчы булып хезмәт иткән Кәрим Хәсән улы белән туган авылы «50 лет СССР» дигән колхозынын торле эшләрендә тырышып хезмәт куйган Халимә Ибрагим кызы гаиләсендә доньяга килгән. Бу гаилә, Шамильдән башка, тагы ике балага – уллары Камильгә һәм кызлары Халисәгә тәрбия биргән, олы тормыш юлына чыгарган.  Шамильнен, барча туган авылы Кvгеш малайлары тосле, елга буенда су коенып, балык тотып балачагы vтә. Мәктәпне тәмамлап, Краснослободск учхозына (бvген ГБПОУ «Краснослободский аграрный техникум») укырга керә. Анда тырышып механик профессиясен vзләштерә. Укуны тәмамлагач, алган профессиясе буенча туган Ельник районы әтисе хезмәт иткән «Сельхозхимия»сенә эшкә урнаша. Бераз анда эшләп алгач, РАЙПОсында механик буларак хезмәт биографиясен дәвам итә. Халык белән бергә яши белә, уртак тел таба белә ул. Ә бvген, тырышлыгы

нәтижәсендә, ООО «За мир» предприятиясе директоры булып хезмәт итә ул. Халыкны азык-толек продуктлары белән тәэмин итvче авыл хужалыгы тармагы яшәешебезнен иминлеген булдыруда топ чыганакларнын берсе булып тора. Шулай «За мир» оешмасы игенчелек, умартачылык белән шогыльләнә, мал-туар vрчетә; эшләре алга бара. Ирешкән унышлары очен, Шамиль Кәрим улы Мещеров, алдынгылар арасында лаеклы урын алды.
Ир кеше доньяга яратылгач, агач утыртырга, йорт салырга, гаилә корырга тиешлеген белеп туа. Һәм Шамиль Кәрим улы барысын да vти: агач та утырткан, ое дә бар, гаиләсе дә. Унышлары да...
- Нык рух, кvтәренке кvнел белән эшләргә язсын, - дигән теләкләр профессиональ бәйрәмнәрендә барча авыл хужалыгы һәм сәнәгать житәкчеләре республикабыз хезмәт-кәрләренә юлладылар.

**Наилә Насырова**